ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында милли-мәдәни автономияләр турында” Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында милли-мәдәни автономияләр турында” 2003 елның 12 маендагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2005, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешендә “хәл итү” сүзләреннән соң “, Россия милләте бердәмлеген ныгыту, этникара мөнәсәбәтләрне камилләштерү, диннәр арасындагы диалогка ярдәм итү, шулай ук мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыруга һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру” сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяның беренче өлешендәге 1 пунктында “үстерү” сүзеннән соң “, Россия милләте бердәмлеген ныгыту, этникара мөнәсәбәтләрне камилләштерү, диннәр арасындагы диалогка ярдәм итү, шулай ук мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыруга һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 5-ТРЗ